Республика Татарстан
Глава Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423647, Менделеевский район, с.Тураево,
ул. Центральная, д 11а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Башлыгы

423673, Менделеевск районы, Турай авылы,
Үзәк урамы, 11а

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 6 ноябреннән № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең
Турай авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы белән, КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлеге Турай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлеге Турай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 21 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлеге Турай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
4. 2020 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлеге Турай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан Турай авыл мәдәният йортын билгеләргә: Турай ав., Үзәк ур., 11 А й.

Турай авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча киләсе тәртиптә башкарыла:

Беренче этап: Кама урамы 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр, Яңа урамы 1 нче йорттан 3 нче йортка кадәр, Яшьләр урамы 8, 10, 21 номерлы йортлар, Окольная урамы 1 нче йорттан 37 нче йортка кадәр.

Икенче этап: Овражная урамы 1 нче йорттан 37 нче йортка кадәр, Совет урамы 1 нче йорттан 33 нче йортка кадәр.

Өченче этап: Үзәк урамы 1 нче йорттан 44 нче йортка кадәр, Крайная урамы 1 нче йорттан 33 нче йортка кадәр.

Дүртенче тап: Тынычлык урамы 1 нче йорттан 18 йотрка кадәр, Мәктәп урамы 1 нче йорттан 12 йортка кадәр.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга::

«2021 елда Менделеевск муниципаль районының Турай авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешерсезме?:

- Мәктәп урамы буенча суүткәргечләрне алыштыру;

- Турай авылы суүткәргече өчен техник план әзерләү килешүе буенча эшләр өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән башлап үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Рәхимова А.М.